Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге
Сосновый Бор поселогы (яңа өлеш )
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«25» ноябрь, 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Сосновый Бор поселогы (яңа өлеш ) граждannar җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2022 елда яшәү урыны буенча Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы (яңа өлеш )территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- су алу җайланмасыннан Сосновый Бор т. п. кадәр (яңа өлеш)суүткәргеч ремонты;
- Сосновый Бор торак пунктында светодиод яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру (яңа өлеш);
- Сосновый Бор поселогында (яңа өлеш) юлларны ремонтлау.

2. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы (яңа өлеш )гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы (яңа өлеш )гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кнәз авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Камалов